МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

улица Бебеля, дом 129,
город Чистополь, 422980

«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Бебель урамы, 129 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

(84342) 5-43-60 … 5-43-70, E-mail …

№

***Постановление*** ***Карар***

Балигъ булмаган гражданнарга
карата опека һәм попечительлек
өлкәсендә дәүләт хезмәтләре
күрсәтүнең яңа редакциядәге административ
регламентын раслау турында

2010 елның 27 маенда кабул ителгән “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 30.12.2017 елгы “Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә урнаштыру мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында”гы 1716 нче номерлы Карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 17 апрелендә кабул ителгән “Татарстан Республикасы дәүләт властеның башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында”гы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында”гы 02.11.2010 елгы 880 нче номерлы Карарының эшләү тәртибенә үзгзрешләр кертү турында”гы 259 нчы карары белән, Чистай шәһәр прокуратурасының 2018 елның 27 ноябрендәге “Муниципаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен көйләүче муниципаль норматив-хокукый актларны тикшерү нәтиҗәләре турында”гы 02-01-16-2018нче номерлы мәгълүматы нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының норматив-хокукый актларын гамәлдәге закон нигезендә тәртипкә китерү максатында, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы башкарма комитетының балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентын яңа редакциядә расларга:

-ятим балалар өчен оешмаларда булган һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны даими рәвештә Россия Федерациясе территориясендә яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында килешү бирү буенча дәүләт хезмәт күрсәтүенең административ регламенты (1нче кушымта);
-балигъ булмаганнар исеменнән сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тартуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәт күрсәтүенең административ регламенты (2нче кушымта);
- даими рәвештә Россия Федерациясе территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының уллыкка (кызлыкка) алучылар булу мөмкинлеге һәм уллыкка (кызлыкка) алучылар сыйфатында кандидат итеп исәпкә куелуы турындагы нәтиҗәне бирү буенча дәүләт хезмәт күрсәтүенең административ регламенты (3нче кушымта);
- балигъ булмаганнарның күчә торган милкен тартып алу буенча килешүләр эшләүгә алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәт күрсәтүенең административ регламенты (4нче кушымта);
- ундүрт яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен алмаштыруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәт күрсәтүенең административ регламенты (5нче кушымта);
- даими рәвештә Россия Федерациясе территориясендә яшәүче гражданнар (түләүле һәм бушлай шартларда) тарафыннан ятим балаларга һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга опека (попечительлек) билгеләү яки опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турындагы нәтиҗәне бирү буенча дәүләт хезмәт күрсәтүенең административ регламенты (6нчы кушымта);
- балигъ булмаганны эмансипацияләү (баланы тулысынча хокуклы дип белдерү) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәт күрсәтүенең административ регламенты (7нче кушымта);
-балигъ булмаганныкы булган күчемсез милекне тартып алу буенча килешүләр эшләүгә алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәт күрсәтүенең административ регламенты (8нче кушымта);
- балигъ булмаганнар катнашында кредит акчасыннан файдаланып, торак сатып алуга һәм аны залогка (ипотекага) тапшыруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәт күрсәтүенең административ регламенты (9нчы кушымта);
- балигъ булмаганның акчалата кертемен алу өчен аның законлы вәкиленә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәт күрсәтүенең административ регламенты (10нчы кушымта);
2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының 05.06.2018 елгы “Балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең яңа редакциядәге административ регламентын раслау турында”гы 430 нчы номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.
3. Чистай муниципаль районы башкарма комитетының опека, попечительлек һәм балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны һәм күзәтүчесезлекне кисәтү буенча бүлегенә (С.А. Сударкинага) әлеге карарны Татарстан

Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый-мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Л.Х. Кәшәповага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов